**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

13 ноябрь 2020 ел № 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге составына керуче Түбән Чыршылы авылында 2021 елда үзара салым кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Югары Чыршылы авыл жирлеге составына керүче Түбән Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Югары Чыршылы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 нче төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 2021 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә

-Түбән Чыршылы авылындагы Горький урамы буенча күперне ремонтлау

- Түбән Чыршылы авылындагы Горький урамына вак таш, асфальт түшәк сатып алу һәм ташу;;

- Түбән Чыршылы авылында артезиан скважинасын буяу һәм буяу эшләре өчен түләү

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Югары Чыршылы авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән,Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рэсми порталында http: //pravo.tatarstan.ru., Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http: //sarman.tatarstan.ru. кабул ителгэннэн соң җиде көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н.Камалетдинов